| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

12.07.2021 Красный Бор авылы № 10-1

Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Красный Бор авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советына чираттагы утырышның көн тәртибенә Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Красный Бор авыл җирлеге органнарының вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү турындагы мәсьәләне карауны кертергә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитетына Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органы белән тиешле килешү төзергә һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карараны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга

һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.Н. Лазарев